7/90
Сентябрь

Салават күпере



Үзең буя!

Әйдәгез, уйныйбыз!

Ватык телефон

Балалар бер рәткә тезелеп утыралар. Бер бала уенны алып баручы була. Ул иң беренче утырган баланың колагына тиз генә бер сүз әйтә. Анысы үз чиратында янындагы иптәшенә пышылдый. Шулай итеп бу сүз, колактан колакка әйтелеп, рәтнең икенче башына барып җитә. Шуннан соң уенны алып баручы сүз барып тукталган баладан: «Нинди сүз?» — дип сорый. Тегесе әйтә. Әгәр сүз дөрес булмаса, уенны алып баручы сүзнең кемдә «бозылганлыгын» эзләп китә. Сүзне кем бозган, ул артка барып утыра һәм уен яңадан башлана. Әгәр сүз дөрес килеп җитсә, уенны алып баручы иң артка барып утыра. Аның алдындагы бала уенны алып баручы була.

кадак

кабак

сабак

табын

табак

чабак

чабан

© «Салават күпере», 1990 ел.



МӘЗӘК

— Бабай, әйт әле, син кайчан бабай булдың? — дип сорый нәни Фәрит.

— Син тугач, улым,— дип җавап бирә аңа бабасы.

— Алайса, моның өчен син миңа нәрсә бирәсең?



Рәссам Ю. ДЕНИСОВ

ТАКМАЗА

Безнең песи бигрәк уңган,
Комганга су тутыра.
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.



ҮРТӘВЕЧ

Җылак, җылак,
Салпы колак,
Карама таяк,
Карт этәч!



ТАБЫШМАК ӘЙТӘМ — ҖАВАБЫН ТАП!

Бер тавык — тавык,
Ике тавык нәрсә?

Тавыклар.

КАРТ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

татар халык әкияте



Бер авылда карт белән карчык яшәгән ди. Бервакыт карт базардан балык алган да кайтырга кузгалган икән. Кайта икән бу, кайта икән... Кайта торгач, караса, юлда бер үлгән төлке ята ди. Карт моңа бик куанган инде.

— Менә бәхет, мин бу төлке тиресеннән карчыгыма тун тектерермен,— дигән дә ул, төлкене алып, чанасына салган. Хәйләкәр төлке балыкларны берәм-берәм чанадан ташлап бетергән дә шыпырт кына үзе дә төшеп калган.

Менә бер заман карт өенә кайтып җиткән. Җәһәт-җәһәт кенә атлап өйгә кергән дә карчыгына кычкырган:

— Карчык, сиңа яңа тун тектерәм, искесен утка як! — дигән.

Карт, төлкене алып керим дип, чанасы янына чыкса, ни күрсен: чанада төлке дә юк ди, балыклардан да җилләр искән ди. Мичтә карчыкның иске туны да янып бетеп бара ди.

Рәссам Ф. МУЛЛАХМӘТ


әкиятхана

РӘХМӘТ!
ТӘМЛЕ БУЛСЫН!
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
ӘССӘЛАМЕГАЛӘЙКЕМ!

Хәерле иртә! Хәерле көн!



Тәмле әйбер ашагач, авызга рәхәт була. Тәмле сүз ишеткәч, күңелгә рәхәт була. Ашый торгач, тәмле әйбер бетә. Ә тәмле сүз... Күпме генә тыңласаң да, күпме генә кабатласаң да, тәмле сүзнең кадере китми, рәхәте әйткән кешегә дә, ишеткән кешегә дә җитә.

Безнең телебездә тәмле сүзләр бихисап! Сез дә беләсез аларны. Төн узып, көн туу белән әйтелә торганына шагыйрь Хәкимҗан Халиков үзенең шигырен багышлаган.



ХӘЕРЛЕ ИРТӘ

Иртән торып чыгуга
Урап алды чебиләр.
Әй сөйлиләр, сөйлиләр:
— Чи-чи, чи-чи-чи...— диләр.

Казлар әйтә: Ка-га-га,
Ә үрдәкләр: Бак-бак-бак.
Нәни бәбкәләре дә:
— Пип-пип,— диләр такмаклап.

Берсен тотып иркәлим,
Икенчесен иркәлим...
Алар: «Пип-пип-пип»,— дисә,
Мин: «Хәерле иртә!»— дим.





Хәерле кич! Тыныч йокы!

Тукта, тукта! Нишләргә?
Әле төште хәтергә:
Әнигә бит шулай дип
Онытканмын әйтергә.



Шушы шигырьне ятлап та алсагыз, өйдәгеләрне, күршеләрне, дусларны «Хәерле иртә!» дип сәламләргә онытмыйсыз инде! Әле тагын «Хәерле көн!», «Хәерле кич!» дигән сүзләребез бар. Алары да онытыла күрмәсен. Хәер, көн саен, кич саен кабатлап торгач, ничек онытылсын ди алар?!

Хуш, көнне кешеләргә яхшылык, дөньяга иминлек теләп башладык. Ә нинди теләк белән тәмамлыйбыз? Шу-лай! Тыныч йокы теләп: «Тыныч йокы, әнием!», «Тыныч йокы, әтием!», «Тыныч йокы үземә, тыныч йокы күземә!»

БИХИСАП — *бик күп, хисапсыз күп.*
ИМИНЛЕК — *тыныч, матур тормыш.*

Рәссам З. МӨХӘММӘТҖАНОВА



Эрәм булган бәрән

Нияз АКМАЛ

Бер бәрән, болында уйнап йөргәндә,
Тилебәрән* орлыгын күргән дә,
Чәйнәмичә дә йотып җибәргән
Һәм шуннан... тилергән бу бәрән.
Тора ди ул бер урында әйләнеп,
Йөри ди ул бүтәннәргә бәйләнеп.
— Сез барыгыз да аңгыра сарык! —
дип әйтеп әйтә ди,—
Мин сездән тәмам гарык! —
дип әйтеп әйтә ди.



Рәссам Ф. ХӘСЬЯНОВА

Турында әкият

— Мин хәзер ауга китәм,—
дип әйтеп әйтә ди,—
Усал бүренең башына җитәм! —
дип әйтеп әйтә ди...
Ул кара урманда тилереп йөргәндә,
Шул усал бүре моның ялгызын күргән дә,
Көлә-көлә шушы тиле-җүләрдән,
Чәйнәмичә аны йотып җибәргән.
Менә шулай итеп бу матур бәрән,
Тилебәрән орлыгы ашап, булган әрәм.

ТИЛЕБӘРӘН — агулы үсемлек.



Кадерле балалар!

Бу сәхифәдә аңлашылмаган урыннар булса, сезгә абый-апаларыгыз, әти-әниләрегез, әби-бабайларыгыз ярдәмгә килер дип ышанабыз.


СЫЕР СҮРӘСЕ **2 НЧЕ СҮРӘ**

213 НЧЕ АЯТЬ. Әллә сез, әле үзегезгә кадәр булып үткән кешеләргә эләккән авырлыкларга тиң авырлыклар күрмичә генә оҗмахка керүне уйлыйсызмы? Аллаһының илчесе рәсүлуллаһ, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр һәм рәсүл белән бергә иман китергән адәмнәр «Аллаһының ярдәме кайчан булыр икән?» дип әйткәнгә кадәр

аларны, ягъни сездән элек булып үткән кешеләрне фәкыйрьлек һәм авырлыклар тотты, төрле бәлаләр белән җир тетрәде, ягъни шул кадәр авырлыкта булдылар ки: сабырдан аерылырга якын булдылар. Аларга: «Аң булыгыз! Чыннан да Аллаһы тәгаләнең ярдәме якын!»— дип әйтелде.

213 НЧЕ АЯТЬКӘ АҢЛАТМА.

Ислам дине барлыкка килгәнче бер иш кешеләр төрле сыннарга, табигать күренешләренә һәм җан ияләренә табынганнар. Аларны мәҗүсиләр дип атап йөрткәннәр. Менә шул мәҗүсиләр, ислам динен кабул иткәч, элекке гореф-гадәтләрдән, төрле йолалардан тиз генә арына алмаганнар. Шул сәбәпле алар күп төрле авырлыкларга очраганнар, сынауларга дучар булганнар. Ул авырлык-сынауларны җиңеп чыккан һәм чын күңелдән Аллаһе тәгаләгә ышанган кешеләр генә оҗмахка керә алачаклар диелә ошбу аятьтә.



Сәхифәне Әнвәр ХӘЙРИ әзерләде.

Рәссам Н. ӘЛМИЕВ

Журналның беренче санында башваткыч-ребус басылган иде. Аның җавабы:

МИН ӘНИНЕ ЯРАТАМ.

Дөрес җавапларны беренчеләр булып җибәрделәр:
Сөмбел һәм Айгөл **Шәфиковалар** (Азнакай),
Гөлшат **Вәлиева** (Казан),
Айрат **Закиров** (Әлки),
Гөлназ **Мостафина** (Зеленодол),
Резедә **Латыйпова** (Түбән Кама).



Песием



Бар минем бик матур пескәем, «Мияу!» — дип сорый ул сөткәен.

Без аны күршеләрдән алып үстердек. Ул хәзер зур булып үсте. Зур булып үссә дә, бик ялкау үзе. Тычкан тотарга яратмый. «Мияу-мияу!» — дип сөт сорап эчә дә, ятып йоклый.


Алисә МИРЗАЯНОВА, 7 яшь.
Мөслим, Татар Бүләре.

Миябикә

Кояш белән бергә тора
Безнең Миябикәбез.
Юына да, сөт эчә дә
Йоклый Юанбикәбез.

Тычкан-күселәрне аулый,
Бәбкәләрне саклый ул.
Бәбкәләрне саклаганда
Рәхәтләнеп йоклый ул.

Гөлнар КАДЫЙРОВА, 14 яшь.
Мөслим, Күбәк.



Алсу НОГМАНОВА, 10 яшь.
Әлмәт, Түбән Мактама.

Заһирә ГОМӘРОВА

Әби, укып бир әле

Әбекәем, килсәнә,
Күзлегеңне кисәнә.
Язу язып утырдым,
Дәфтәремне тутырдым.

Үзем яза белсәм дә,
Күзем яхшы күрсә дә,
Укый белмим бит әле,
Әби, укып бир әле.





Фирая ЗЫЯТДИНОВА

Күзем йомылмый...

— Йокла, улым, соң бит инде,
Йокла, йокла, улым, дим...
— Үзем дә бик йоклар идем,
Никтер күзем йомылмый...

Энҗе МӨЭМИНОВА

Уенчыклар кибетендә

Нигә кирәк миңа мылтык?! —
Куянга атаргамы?
Бүрегә атаргамы?
Әллә абый белән бергә
Атышып ятаргамы?
Кирәк түгел миңа мылтык! —
Аңладым...
Бик кызыктырып торса да,
Алмадым.



Рәссам А. ҮТӘГӘН



Сезнең өйдә, ишегалдыгызда, бакчагызда Г хәрефеннән башланган тагын нәрсәләр бар?



Рәссам А. ТИМЕРГАЛИНА

ӘКИЯТИ БАШВАТКЫЧ

Шакмакларны дөрес итеп тутырсагыз, төсле баганада бер сүз пәйда булыр.

1. Дию пәриләре башлыгы.

2. Сихерле лампа хуҗасы.

3. Алыплар коралы.

4. Татар халкының «Кыйна, әтәч!» әкиятендәге ике туганның берсе.

5. Убырлы карчык килене, әниләренә кунакка җыенып, юлда күп михнәтләр күргән гүзәл хатын.

ТАБИГАТЬТӘ КУНАКТА



САРУТ

(Пырей ползучий)

«Чүп үләне», диеп кенә
Уйлый күпләр — беләм мин.
Белмәгәннәр өчен әйтәм:
Бик файдалы үлән мин.

Дару да мин, ризык та мин —
Булганда ак тамырым...
— Татлы тамыр миндә ул! —
дип
Мин сезгә мактанырмын.


Башка төр исемнәре: шуышма сарут, актамыр. Сарутның татлы тамырын аш пешергәндә, салат әзерләгәндә тәмләткеч итеп кулланалар. Шундый ук тамырдан хәстәрләнгән төнәтмә ашказаны-эчәк авыруы булган кешеләргә файдалы (бер стакан кайнар суга — бер аш кашыгы вакланган-төелгән тамыр).

Сарут — иген басуында аяусыз чүп үләне, ә көнкүрештә — ризык.

Рәшит БӘШӘР

БАКЧАДА

Чәчәккә үрелүгә,
Сизде бугай уемны:
— Өз-з-з-з-змә! — диеп бал корты
Чагып алды кулымны.



Рәссам Л. ЗОЛОНДИНОВА



Хәйдәр Сәлим

Хәйдәр Сәлим хәзерге Куйбышев өлкәсе Мәләкәс районы Мукшы Күле авылында 1884 елда дөньяга килә. 1913-1915 елларда Казанда чыккан балалар журналы «Ак юл» да шигырьләрен бастыра. Гомеренең соңгы елларында мөгаллим (укытучы) була.



КҮГӘРЧЕН АВЫЗЫННАН

— Гөлдергү-ү, гөлдергү-ү!..
Бигрәк чибәр, кемдер бу?
Тарап үргән чәчләре,
Өсте-башы бик ару.

— Гөлдергү-ү, гөлдергү-ү!..
Бер әдәпле кыздыр бу.
Мәктәп дигән бакчада
Чәчәктер бу, гөлдер бу!





КАРГА БЕЛӘН ЧӘУКӘ



Карга әйтә: Карр-карр!
Гариф укый начар...
Өсте-башы тузанлы,
Китаплары буяулы.

Чәукә әйтә: Чарр-чарр!
Гарифта да дәрт бар,
Ялкаулыгын ташлады,
Хәзер укый башлады.

зак диңгезе һәм Каф таулары итәгенә урнашкан Бөек Болгар дәүләтенең бәхетле еллары озак дәвам итми.

Шәһәрләр буйлап сөрәнчеләрнең аянычлы авазлары киң урамнарга, аулак тыкрыкларга тарала, тәрәзәләргә бәрелеп җанга тия. Барабаннар дөңгерди, быргылар сузып-сузып елый. Далалардагы җәйләүләргә атчабарлар җилдерә.

Һәр кешенең йөрәгендә кайгы.


Һәр кешенең күзендә яшь.

Хан үлгән!

644 елда Кубрат хан башка дөньяга күчә. Аны иң затлы киемнәргә киендерәләр, биленә кылыч тагалар, янәшәсенә дә кораллар куялар. Ханны аты белән бергә җирлиләр. Теге дөньяда да Кубрат хан дошманнары белән алышыр, теге дөньяда да җиңүләр яулар. Янәшәдә алтын табаклар белән ризыклар да була. Сугышлардан соң аның тамагы ачар ич, ул туйганчы ашар һәм бөек Тәңрегә рәхмәтләр укыр. Болгарлар борынгы заманнарда үлгәннән соң да тормыш дәвам итә дип уйлаганнар.

Далада тагын бер курган барлыкка килә. Аның астында дошманнарын тетрәтеп торган Кубрат хан мәңгелек йокыга тала.

Аскакаллар, вәзирләр, гаскәр башлыклары киңәшкә җыела. Дәүләт хансыз яши алмый... Кем хан булыр? Кубратның кайсы улы? Батбаймы, Аспарухмы, әллә инде иң төпчек улымы?



Рәссам Р. ШӘМСЕТДИН



Мәхмут Хәсән

— Карасана, кара, Сара укырга бара!..

Әлеге яңалык иң әүвәл, нәни оныклары белән ишегалдына чыккан әбиләрне, гәп сатып утырган апаларны хәйранга калдырды: «Күрче, зинһар, кай арада үсеп җиткән диген син аны!»

Ә инде Сара үзе күренгәч, комлы әрҗә эчендә уйнап утырган бала-чагалар да, гаҗәпләнүдән авызларын ачып, тынып калдылар.

Ул иртәдә Сара, чыннан да, карап туймаслык иде. Өстендә күз явын алырлык ак алъяпкыч, аякларында сыек саргылт төстәге өр-яңа сандаллар. Чәчләренә күк йөзе кебек җете зәңгәр «күбәләк» кунган. Янында, кулына чәчәк бәйләме тоткан әнисе белән әтисе.

Сара комлы әрҗә эченә җыелган дус-ишләре янына килмичә булдыра алмады.

— Мин бүтән сезнең белән уйный алмам инде... Мәктәпкә укырга барам. Әби дә: «Син үскән, зур кыз хәзер, тузанга батып комлыкта уйнау сиңа килешми»,— диде...

...Көннең икенче яртысында әбиләр, апалар үзләренең оныкларын янә ишегалдына алып чыктылар. Комлы әрҗә тирәсе яңадан бала-чагаларның чыр-чуы, шау-шуы белән тулды. Бу юлы инде дөньяларын онытып мәж килеп уйнаучылар арасында өсбашын алыштырып чыккан Сара да бар иде.

Йокла инде, курчагым!


ӘНИЛӘРГӘ
һӘМ
НӘНИЛӘРГӘ

БИШЕК ҖЫРЫ

Әминә БИКЧӘНТӘЕВА шигыре
Мәсгут ИМАШЕВ көе

Ашыкмыйча









Зәңгәр күзле курчагым,
Әлли-бәлли ит әле.
Синең бит йоклар чагың,
Тәмләп йоклап кит әле!

Аргансың инде, җаным,
Йокла, минем матурым.
Мин дә синең яныңа
Ял итәргә ятармын.

Йокла инде, курчагым,
Йомылмаса да күзең.
Сине йоклата торгач,
Йоклап китәм бит үзем.



Рәссам А. ТИМЕРГАЛИНА

Салават күпере

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ ВЛКСМның ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА КОМИТЕТЫНЫҢ НӘНИЛӘР ӨЧЕН АЙЛЫК ЖУРНАЛЫ
1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН ЧЫГА

БАШ МӨХӘРРИР
ЗИННУР ХӨСНИЯР

ИДАРӘ

Шәүкәт ГАЛИЕВ,
Фирая БӘДРЕТДИНОВА
(җаваплы сәркатип),
Ләбиб ЛЕРОН
(бүлек мөхәррире),
Роберт МИҢНУЛЛИН,
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,
Солтан СӘЛИМҖАНОВ,
Мәгъсум ХУҖИН,
Фәридә ХӘСЬЯНОВА,
Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,
Асия ЯРУЛЛИНА

Бизәлеш мөхәррире
Айдар ҮТӘГӘН

Тышлыкның беренче битендә **Е. ХИТРОВА** рәсеме, дүртенче битендә **М. МЕДВЕДЕВ** фоторәсеме

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты
Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТССР и Татарского РК ВЛКСМ для малышей. Издается при участии Советско-Финской фирмы «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году. Адрес редакции: 420012, г. Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 30.06.90 ел. Басарга кул куелды 3.09.90 ел. Кәгазь форматы 84 × 108 1/16. Басма табак 1,0(2,1). Учет. издат. табак 3,09. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 25044. Заказ Д-315.
Бәясе 50 тиен.



Бәясе 50 тиен.

ISSN 0868—4545



БЕЗНЕ, НӘНИЛӘРНЕ, МАТУР РӘСЕМНӘРЕ БЕЛӘН КУАНДЫРЫР «САЛАВАТ КҮПЕРЕ». ӨЛКӘННӘР БЕЗГӘ ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘГЕ МАҖАРАЛЫ ӘКИЯТЛӘРНЕ УКЫП КҮРСӘТЕРЛӘР. БЕЗ «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НДӘГЕ БИШЕК ҖЫРЛАРЫН ТЫҢЛЫЙ-ТЫҢЛЫЙ ӘЛЛИ-БӘЛЛИ ИТӘРБЕЗ. САЛАВАТ КҮПЕРЕДӘЙ ТӨСЛЕ, МАТУР ТӨШЛӘР КҮРЕРБЕЗ!..